ГЛАВА КИЛЬДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КИЛДИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06.10.2020 с. Кильдеево 4

Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Уланово авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Уланово авылы гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 21 октябренә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлегенең Уланово авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә риза булырсызмы:

- Уланово авылы су башнясының беренче санитар зонасын төзекләндерү

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын Уланово авылы, Заозерная урамы, 44 йорт адресы буенча 14.00 сәгатьтә Уланово авыл клубында үткәрергә .

4. Җыенны оештыручы итеп Килди авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге башлыгы В. М. Бурдин